
# XIX ГАСЫР ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КАЗАН ОБРАЗЫ



**И.Г Гомәров** (КДУ)

XIX йөз – күпгасырлык татар мәдәниятенең гаять катлаулы, каршылыклы һәм мөһим үсеш чоры. Феодаль-крепостнойлыктан капитализмга күчә бару, буржуаз-демократик һәм мәгърифәтчелек хәрәкәте нигезендә милли аң формалашу, Ислам диненең әхлакый сыйфатларына таянып милли алгарыш принциплары барлану аның асыл билгеләрен тәшкил итә. Нәкъ шушы гасырда татар халкы милләт буларак оешу юлына аяк баса. Иҗтимагый-фәлсәфи фикер үсешендәге үзгәрешләр халкыбызның рухи тормышына, мәдәниятенә, сүз сәнгатенә дә сизелерлек йогынты ясый. Бу чорда әдәбиятның асыл рухы, үсеш-үзгәреш юнәлешләре билгеләнә, аның идея-эстетик табигате тәгаенләнә бара.

Бүген XIX йөздәге милли алгарышның, иҗтимагый аңның чагылышы булган әдәби мирасны кабат барлау, аңа заман ихтыяҗларыннан чыгып объектив бәя бирү әдәбиятыбызның, гомумән алганда, җәмгыятебезнең үсеш принципларын дөрес билгеләргә ярдәм итә.

Мәгърифәтчелек чоры үзенең кыю рухлы булуы белән аерылып тора. Яңа идеология моңа кадәр яшәп килгән феодаль-кадими тәртипләрне аек акыл һәм социаль гаделлек ноктасыннан торып тәнкыйть итә. Иҗтимагый-мәдәни хәрәкәт сыйфатларын үз эченә алган Мәгърифәтчелек яңа эчтәлек һәм формага ия булган мәгърифәтчелек әдәбиятын мәйданга чыгара. Фәлсәфи рух һәм актив характер бу төр сүз сәнгатенең төп компонентларыннан санала. «Әдипләр катып калган дидактизм, синкретизм традицияләреннән читләшеп, сәнгатьчә фикерләүнең дөньяви стандартларына якынлашалар... XIX гасыр әдәбиятында тәэсирлелек, активлык, әһәмиятлелек аның дәрәҗәсен күтәрүче специфик сыйфатларына әверелә» [1, 3].

XIX йөз – Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов, Ризаэддин Фәхреддин кебек энциклопедик белемле каләм ияләрен, Габделҗәббар Кандалый, Мифтахеддин Акмулла, Гали Чокрый, Мәүлекәй Йомачиков, Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев, Фатих Халиди, Фатих Кәрими һәм башка мәгърифәтче әдипләрне биргән гасыр.

Мәгърифәтчеләрнең әдәбиятка алып килгән яңалыгы, иң беренче чират-та, алар мөрәҗәгать иткән социал-иҗтимагый проблемаларда ачык чагыла. Нәкъ менә алар иҗатында шәхес азатлыгы мәсьәләсе, шәхес һәм җәмгыять, шәхес һәм милләт мөнәсәбәтләре кискен яңгыраш ала, милли алгарыш өчен киртә булган барлык күренешләр ачы тәнкыйть утына тотыла.

«Мәгърифәтчелек әдәбияты» төшенчәсе үз эченә аерым бер эстетик сыйфатларны гына берләштерми. Төрле халыкларның мәгърифәтчелек әдәбиятларын бер-берсеннән аерып торучы төп билге – аларның үзләренә генә хас милли үзенчәлекләре.

Аурупа һәм Шәрык сүз сәнгате контекстында караганда, татар мәгърифәтчелек әдәбиятында да аның милли йөзен билгеләүче сыйфатлар булуы ачык күренә. «Билгеле бер эстетик системаның моделе буларак, төрле милли әдәбиятларда классик мәгърифәтчелек әдәбиятының төп идея һәм эстетик тенденцияләрен саклау принцибы» үтәлгән хәлдә дә, Аурупа яки рус мәгърифәтчеләре белән татар мәгърифәтчеләре арасына тигезлек билгесе кую дөрес булмас иде. Биредә татар әдипләренең үзгә милли-тарихи һәм социаль-иҗтимагый шартларда эшчәнлек алып барганнарын исәпкә алмый мөмкин түгел. Бу чорда ислам динендәге татарларның төп халкы христиан динен тоткан Россия дәүләте составында яшәүләре дә әлеге аерымлыкны билгели.

Мәгърифәтче язучыларның әдәби-эстетик карашлары һәм иҗат принциплары турында сүз йөрткәндә әсәрләренә сурәтләү предметы итеп татарның үз тормыш-көнкүреш материалы алынуын искәртү урынлы булыр. Моны бу чор әсәрләрендә бөтен татарның уртак ватаны булган Казан шәһәре тасвиры аша да күзәтергә мөкин. XIX йөздә Казан мөселман дөньясының гына түгел. Европа илләре өчен дә сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәкләрнең берсенә әверелә бара. Табигый ки, бу әлеге чор әдәбиятында да чагылыш таба, Казанга багышлап әсәрләр иҗат ителә. Еш кына аларда Казан теге яки бу вакыйга уңае белән генә түгел, ә аерым бер әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнеш таба. «Киң иҗтимагый-географик мәйданда яшәүче бер халыкның әдәбияты өчен Казанның иҗтимагый культура үзәге булуын тану һәм әдәби сурәтләү 1880-1890 елларда мөһим бер темага әверелә һәм төрле төбәкләрдәге каләм ияләренең төрле жанрлардагы әсәрләре тууга сәбәпче була» [**6**, 42-43].

XIX йөзнең соңгы чиреге-XX гасыр башында язылган Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан» (1889), Мөхәммәд Йосыфның «Казан голямәсе, мөдәррис вә мәсаҗиде хакында» (1894) әсәрләре, Тукай каләменнән төшкән «Пар ат» (1907), «Печән базары яхуд яңа Кисекбаш» (1908), «Казан» (1913) кебек шигъри ядкярләр – әнә шундыйлардан.

Бу уңайдан рус сүз сәнгатенә дә күз салу урынлы булыр. Әйтик. мәгърифәтчелек чоры рус әдәбиятындагы Петербург образы хакында шагыйрь В.Рождественский болай дип яза: «XVIII век – век рационализма, четко очерченных моральных догм. Абсолютизм верховной власти, несколько подправленный осторожным просветительством, казался высшим достижением дворянского общественного долга. Поэты... сочиняли по торжественным случаям высокопарные оды, прославляющие царствующих персон и деяния самодержцев российских. Естественно. неизменным фоном этих восхвалений явился облик новой столицы государства. Петербург в одической

поэзии стал символом торжествующего и просветающего самодержавия» [3, 3].

Бу фикерләр күпмедер күләмдә XIX гасыр татар әдәбияты өчен дә хас. Тик биредәге мәдхияләрнең макталу объекты, без алда искә алган мәгълүм сәбәпләр буенча, патша һәм монархлар түгел, татарның милләт маягы – алдынгы карашлы дин, мәгариф эшлеклеләре. Безнең фикеребезчә, аларда Казанның Дарел-Ислам *(Ислам йорты)*, гыйлем-мәгърифәт мәркәзе буларак сурәтләнеш табуы да, иң беренче чиратта, шуның белән бәйле. Шуңа күрә Мифтахеддин Акмулла Шиһабеддин Мәрҗанигә багышланган мәрсиясен: «Казанда бер фазыйл *(галим)* чыкды алмаз булып», дигән юллар белән башлый, ә Мөхәммәд Йосыф: «Икенче дәлилем будыр, / Гыйлем җорты Бохарадыр, / Казан Рәсәйдә саелыр, / Гүя икенче Бохарадан», дип яза үзенең «Казан голәмәсе, мөдәррис вә мәсаҗиде хакында» исемле китабында.

Шунысы мөһим: югарыда телгә алынган шигъри ядкярләрдә Казан каласы әдәби фон вазыйфасын үтәсә, XIX йөзнең икенче бер олы шагыйре Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан» *("Казанга мәдхия")* әсәрендә аерым бер әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелә. Автор биредә, илһамланып, Казанның тышкы күренешен, табигатен тасвирлый, андагы йорт-җирләрнең төзеклегенә, мәчетләрнең күплегенә хәйран кала, шушы гүзәллекне тудыручыларның эш-гамәлләренә, аларның инсафлылыгына, олы күңелле булуларына соклануын белдерә. Әмма шагыйрьнең соклануы бер яклы гына түгел, ул әлеге матурлыклар артында үз халкының гасырлар дәвамында кичергән чиксез моң-сагышын, ачы хәсрәтләрен дә ачык тоя. Автор укучыга "гыймарәт форсаты йөз сал" *(йортларын, төзелешләрен күр)* алар барысы да халыкның "михнәти", газаплы һәм фаҗыйгалы язмышын чагылдыралар, ди.

Бу әсәрендә Гали Чокрый сүз белән сурәт ясауда географик детальләрдән оста файдалана. Әсәрдәге «ләтаиф әүсафы мәрсүм *(матур сыйфатлары билгеле)*, Кабан күл ягы да мәнзум *(чиста, тәртипле)*», «Бишбалта, Порхавой Казан хөкмендә гали *(югары)* җай» кебек тасвири сыйфатлар аша шәһәр пейзажы туа.

Шагыйрь Казанның йортларын, мәчетләрен күздән кичерә, аларның күплегенә, матурлыгына таң калып, «тәмам зиннәт илә сәздыр» дип яза. Мәчетләрнең күпчелеге санап үтү рәвешендә искә алынса, Хан мәчетенә аерым шигъри юллар багышланган:

Йәнә Хан мәсҗеде дә бар бу иске бистәдә әй, йар,

Манарасы гали, азһар, васыйф тәшһир илә саздыр

*(Манарасы һәр җирдән күренә, мактап сөйләүгә лаек).*

Шул рәвешле, әлеге архитектур корылма Казанның идея-эстетик йөзен билгеләүче символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Петербургтагы 1782 елда Фальконе тарафыннан иҗат ителгән Бакыр җайдак (Медный всадник) сыны рус әдәбиятында А.Пушкин, Н.Огарев, А.Блок, В.Брюсов һәм башка бик күп язучылар әсәрләрендә шәһәрнең архитектур һәм идея-эстетик сыйфатларын чагылдыручы символик образ булса, Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан»ында сурәтләнеш тапкан Хан мәчете дә шундый ук вазыйфаны үти дияргә мөмкин.

Шагыйрь Казанны матурлыкның сәнгатьчә югары дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән йортлары, зиннәтле мәчетләре өчен генә данламый. Ул бу корылмаларны шушында яшәгән халыкның тырыш хезмәт нәтиҗәсе итеп күзаллый. Әдип өчен әлеге шәһәр – тере социаль организм. Казан «ләбибләр... әдипләр... табиблар күплеге берлә», алар тудырган гүзәл эшләр белән бар җиһанга мәшһүр кала.

Татар халкының тырышлыгы, эш-һөнәргә осталыгы турында сөйләгәндә әсәр тукымасына этнографик элементлар да уңышлы кертеп җибәрелә. Әдип фикеренчә, казанлылар тарафыннан тегелгән кием-салым, калфак, читек, башмак галәм халкы алдында мактауга лаек.

Шагыйрьнең: «Йәнә анда хатын-кызлар тегү-чәнчү нәкыш дәйар *(тегү-чигүдә осталар)*», дип татар халкында чигү сәнгатенең алга киткәнлегенә игътибар итүе дә очраклы күренеш түгел. Әлеге һөнәрнең ерак тамырлары хакында «Әдәби сүзлек»тә болай диелгән: «Татар халкының чигү сәнгате күп гасырлар буена өзлексез үсә-камилләшә килгән. Аның традицияләре дә безнең бабаларыбыз Идел буе болгарларына һәм Казан ханлыгы чорына барып тоташа. Археология материалларына караганда, мәсәлән, ефәк җепләр белән алтынлап һәм көмешләп чигү ысулы Болгар халкы арасында киң таралган булган» [**6,** 235]. Димәк, бу алым авторга укучы күңелендә болгар-татар тарихи дәвамчанлыгының өзлексезлеген тагын бер кат искә төшерергә мөмкинлек бирә.

Татар халкының милли йөзен, характер-сыйфатларын аның этник киемнәре, билгеләре аша ачарга омтылыш – XIX гасыр шигърияте өчен чагыштырмача яңа күренеш. Бу – әдәбиятның идея-эстетик сыйфаты ягыннан яңа баскычка күчә бару дәлиле. Гали Чокрый кулланган этнографизм алымын соңрак башка татар язучылар да үз итә. Бу бигрәк тә, әдәбиятыбыз классигы Гаяз Исхакый иҗатында тотрыклы традициягә әверелә.

Җыеп әйткәндә, «Мәдхе Казан» әсәрендә Казан аерым бер шәһәр буларак кына тасвирланмый, ә татар халкының үткәнен һәм киләчәген символлаштыручы, милли йөзен билгеләүче образ дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнелә. Биредәге тарихи мотивлар әдипнең милли һәм ватанпәрвәрлек хисләре белән симбиоз рәвештә үрелеп бара. Автор Казанны Болгар дәүләтенең тулы хокуклы варисы буларак, ягъни болгар-татар тарихын бербөтен процесс итеп күзаллый. Әлеге фикер әсәрнең:


Мәгәр Болгарны һәб гамләр *(барча халык)* тәмам империя диб аңлар,

Тәмам Болгарда нәләр бар – күбе монда назар саздыр *(чагылыдыр)*,

дигән юллары аша да ачык аңлашыла. Казан каласын Болгар шәһәрләре белән чагыштыру рәвешендәге «Берәрсе киләме парга, кеме Казан мисал саздыр?!» *(Казан белән тиңләшерлек)* риторик соравында шагыйрьнең үз ватаны өчен горурлык хисен, ватанпәрвәрлек мотивларын да аермачык тоярга мөмкин.


ИСКӘРМӘЛӘР

1. *Гайнутдинов М.В.* Татарская литература XIX века (Идейно-художественный генезис и исторические судьбы): Дис. в виде научного докл. на соиск. уч. степени доктора филол. наук. – Казань, 2000.
2. *Петербург* – Петроград – Ленинград в русской поэзии. – Л,: Лениздат, 1975.
3. *Рәми И.Г., Даутов Р.Н.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.
4. *Фәтхи А.С.* Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары//КДУ фәнни китапханәсенә 1959–1969 елларда кергән кулъязмаларның тасвирламасы. – Казан: КДУ нәшр., 1986.

XIV гасыр төрки-татар истәлеге "Булгат ал муштак фи лугат ат турк ва-л-кифчак"ның телен тикшерүгә багышланган китап басылып чыкты. Аның авторы – филология фәннәре кандидаты Г.Р.Гайнетдинова. Авторың үзенә мөрәҗәгать итә аласыз.